

Жинv Коне алдыннан Зубово-Поляна районы Горенка мәктәбенен укучылары Кочетовка авылында яшәvче Боек Ватан сугышы еллары балаларында – Магирә Саберджан кызы Немишева белән Магинур Хосәен кызы Маминада кунакта булганнар. Балалар, алар очен котлаулар һәм чәчәкләр әзерләп тапшырганнар. Очрашу бик дулкынландыргыч булган: олылар мәктәп укучыларынын игътибарына һәм кайгыртуына шатланганнар. Шулай ук бу балалар Горенка, Кочетовка, Калиновка, Русский Лундан белән Татарский Лундан олыларын 9 май бәйрәме белән котлаганнар.       Боек Жинv бәйрәме алдыннан vткән очрашуда Магинур Хосәен кызы Мамина белән Магирә Саберджан кызы Немишева укучыларга Боек Ватан сугышы елларынын авырлыклары һәм гаиләләре турында сойләгәннәр. Ә балалар, сулышларын алырга да онытып, хикәяләрне тынлаганнар һәм зур кызыксыну белән сугыш турында сораулар да биргәннәр. Шулай ук аларга нык сәламәтлек, озын гомер, ботен доньяга тынычлык теләп чәчәкләр бvләк иткәннәр укучылар. Бу әбиләр сугыш вакытында һәм аннан сонгы чорда vскәннәр, димәк, жимереклек белән корәшкәннәр, илне кvтәргәннәр. Аларга сугыштан сонгы чорда башкарган батырлыклары очен рәхмәт белдергәннәр. Киләчәк буын кешеләренен бурычы - аларга йорәкләребездә булган жылылык кисәген бvләк итv. Хәтер йорәкләрдә.

*Фото «Горенская ООШ» сайтыннан*